| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы**<br>**Арча муниципаль районының**<br>**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**<br>**Арча шәһәр Советы**<br>**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**<br>**тел. 3-16-25, 3-12-35** | **Муниципальное образование**<br>**город Арск**<br>**Арского муниципального района**<br>**Республики Татарстан**<br>**Совет города Арск**<br>**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**<br>**тел. 3-16-25, 3-12-35** |

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**"15" июнь 2020 ел** **№ 147**

**Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Уставының 14 статьясы нигезендә Арча шәһәре Советы **карар бирде**:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы арча шәһәре Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча "Арча хәбәрләре" ("Арский вестник") район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында Арча ш., Совет мәйданы, 27 йорт; Арча ш., Совет мәйданы, 25 йорт; Арча ш., Х. Такташ ур., 58 йорт, Арча шәһәре, Кленовая урамы, 4 йорт; Арча шәһәре, Банк урамы, 2А йорты адреслары буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев

«Совет города Арск»
ОГРН 1121690009220
ИНН 1609012686